ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 март 2019ел № 1613

Башкарма комитетның «2015-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 7047 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 нчы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2015-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 7047 нче карарына (Башкарма комитетның 2014 елның 8 декабрендәге 7609 нчы, 2016 елның 30 мартындагы 1423 нче, 2016 елның 20 маендагы 2539 нчы, 2018 елның 12 мартындагы 1243 нче, 2018 елның 6 сентябрендәге 4995 нче карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлектәге 1.1 пункт белән тулыландырырга:

«1.1. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2015-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын финанслауны шәһәр бюджетының «Гомумдәүләткә караган башка мәсьәләләр» 01.13 һәм «Яшьләр сәясәте һәм балаларны сәламәтләндерү» 07.07 бүлекләрендә (бүлекчәләрендә) каралган акчалар хисабына 611 843,6 сум, шул исәптән: 2015 елда – 20 000 сум, 2016 елда – 120 000 сум, 2017 елда – 120 000 сум, 2018 елда – 111 843,6 сум, 2019 елда – 120 000 сум, 2020 елда – 120 000 сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) «2015-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасында:

- «Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары (еллар буенча бүлеп)» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 |
| | Муниципаль бюджет | 20000 | 120000 | 120000 | 11843,60 | 120000 | 120000 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 20000 | 120000 | 120000 | 111843,60 | 120000 | 120000 |

- 4 бүлекнең 4 пунктындагы 34.1, 34.2, 34.3 пунктчаларны кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 29 мартындагы
1613 нче карарына
кушымта

## 4 бүлек. Программа чараларының исемлеге һәм кыскача тасвирламасы

Программа чараларының исемлеге һәм кыскача тасвирламасы:

| Т/с | Чараның исеме | Башкаручы | Үтәү срогы | Көтелгән нәтиҗә | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау | Еллар буенча чыгымнар суммасы, мең сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 4. Коррупциягә каршы белем һәм коррупциягә каршы пропаганда | | | | | | | | | | | |
| 34.1 | «Тикшерү алып барыла» интеллектуаль-мәгълүмати квест оештыру | «Нур» ЯҮ» МАУ (килешенү буенча) | 2015-2020 | Мәктәп укучыларын һәм студентларны коррупциягә каршы тәрбияләүне методик тәэмин итү | Шәһәр бюджеты | - | 28 | 28 | 27,115 | 28 | 28 |
| 34.2 | «Коррупциягә юк дип әйт!» белем бирү-танып белү квесты оештыру | «Нур» ЯҮ» МАУ (килешенү буенча) | 2015-2020 | Коррупциягә карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру | Шәһәр бюджеты | - | 39 | 39 | 28,95060 | 34 | 29 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 34.3 | «Гадел белемнәр» коррупциягә каршы интеллектуаль-танып белү уены оештыру | «Нур» ЯҮ» МАУ (килешенү буенча) | 2015-2020 | Коррупциягә карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру. Студентларның РФ һәм РТның гамәлдәге законнары турында мәгълүмат алуы | Шәһәр бюджеты | - | 33 | 33 | 30,778 | 33 | 33 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова